ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МЕНДЕЛЕЕВСК МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ПЕСӘЙ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕНЕҢ ТАТАР САРСАЗЫ
ТОРАК ПУНКТЫНДА ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ
КАРАР

13.11.2025 ел № 2

2026 елда Татарстан Республикасы
Менделеевск муниципаль районы Песәй
авыл җирлегенең Татар Сарсазы
авылында гражданнарның үзара салым
акчаларын кертү турында

«Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль законның 45, 69 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Песәй авыл җирлеге башлыгының “Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Песәй авыл җирлегенең Татар Сарсазы авылында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында” 2025 елның 1 ноябрендәге 3 нче номерлы карары нигезендә Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Песәй авыл җирлегенең Татар Сарсазы авылында гражданнар җыены КАРАР КЫЛДЫ:

1. «2026 елда Менделеевск муниципаль районы Песәй авыл җирлегенең Татар Сарсазы авылында яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 1000 сум күләмендә үзара салым акчаларын I-II төркем инвалидлардан, тыл ветераннарыннан, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннарыннан, балигъ булмаган күп балалы гаиләләрдән, югары һәм урта уку йортларының көндезге бүлегендә укучы студентлардан, Россия Армиясенә сроклы хезмәткә чакырылган гражданнардан 500 сум күләмендә, Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган гражданнар һәм аларның гаилә әгъзаларын түләүдән азат итеп, кертергә һәм алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен түбәндәге ихтыяҗларга юнәлтергә:

“1) торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияткә ия булган автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (Татар Сарсазы авылының Куйбышев, Елга, Урман урамнары буйлап юлларны ремонтлау (вак таш, асфальт валчыклары сатып алу, тигезләү), Татар Сарсазы авылындагы юлларны кардан чистарту);

2) урамнарның тышкы яктырту челтәрләрен, трансформатор һәм башка подстанцияләрне һәм алар астындагы мәйданчыкларны, бүлү пунктларын һәм электр элемтәләрен тәэмин итү һәм электр энергиясен тапшыруны гамәлгә ашыру өчен

билгеләнгән башка җайланмаларны ремонтлау (Татар Сарсазы авылында яктырткычларны алыштыру). »

2. Әлеге карарны кабул ителгәннән соң 10 көн эчендә мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru һәм www Менделеевск муниципаль районының рәсми сайтында http:///mendsleevsk.tatarstan.ru “Песәй авыл җирлеге” бүлегендә бастырып чыгарырга.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Менделеевск муниципаль районы
Песәй авыл җирлеге башлыгы ____________ В.И.Мөхәммәтгалеев

(имза) (имзаны киңәйтү)